СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«СТАРОШУГУРОВСКОЕ
СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»
ЛЕНИНОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«ИСКЕ ШӨГЕР
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ

КАРАР

2023 елның 1 марты №1

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Иске Шөгер авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2015 елның 26 октябрендәге 7 номерлы карарына үзгәреш кертү хакында (15.10.2018 № 23, 29.11.2018 № 29 үзгәрешләр белән)

Россия Федерациясе Салым кодексының 406 статьясы нигезләмәләре нигезендә, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Иске Шөгер авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Иске Шөгеравыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2015 елның 26 октябрендәге 7 номерлы карарына (15.10.2018 № 23, 29.11.2018 № 29 үзгәрешләр белән)түбәндәге үзгәрешне кертергә:

күрсәтелгән карарның 2 пунктының 1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) 0,1 процентка карата:

- гараж һәм машина урыннары;

- һәрберсенең мәйданы 50 квадрат метрдан артмаган һәм шәхси ярдәмче хуҗалык, яшелчәчелек, бакчачылык яки индивидуаль торак төзелеше алып бару өчен җир участокларында урнашкан хуҗалык корылмалары яки корылмалары;

- Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 7 пункты нигезендә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органы тарафыннан билгеләнә торган салым салу объектларында, шул исәптән исемлеккә кертелгән салым салу объектларында урнашкан гаражлар һәм машина урыннары;».

2.Әлеге карарны Иске Шөгер авылы, Совет урамы, 1 йорт, Совет урамы буенча балалар бакчасы бинасы 3 нче йорт, М. Җәлил урамы буенча 33 нче йорт, Яңа Шөгер авылы, Гагарин урамы, 1/А адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (https://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (https://pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар, рәсми басылып чыккан көненнән бер айдан да иртәрәк булмаган вакытта, 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Лениногорск муниципаль районы
«Иске Шөгер авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы,
Совет рәисе Л.М.Шиһапова